**ISPEC International Journal of Social Sciences & Humanities**

**E-ISSN: 2717-7262**

**Vol: 3, Issue: 1, 2019**

# MODERN TURKISH LANGUAGES IN CONDITIONS OF GLOBALIZATION: CONCERNING PROTECTION AND DEVELOPMENT

**Г.Ә.Нәбиуллина**

*Филология фәннәре кандидаты*, *доцент*, Казан федераль университеты, guzelnab2@yandex.ru

**Abstract**

There are currently twenty-six Turkic nations officially registered in the world. Today, the Turkic-speaking population is 300 million. is shown to be around. The vast majority are Tatars, Bashkirs, Turks, Azerbaijanis, Chuvash, Uzbeks, Turks, Karchai-Balkars, and others. peoples make up. Although our spoken language and literary language today are independent, there are considerable differences between sister languages.

**Keywords:** modernity, turkish language, globalization

# ГЛОБАЛЬЛӘШҮ ШАРТЛАРЫНДА ХӘЗЕРГЕ ТӨРКИ ТЕЛЛӘР: САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕНӘ КАРАТА

**Тамгалау**

Хәзерге вакытта дөньяда рәсми рәвештә теркәлгән егерме алты төрки милләт исәпләнә. Бүгенге көндә төрки телләрдә сөйләшүче халык саны 300 млн. тирәсе дип күрсәтелә. Зур күпчелекне татар, башкорт, төрек, әзербайҗан, чуваш, үзбәк, төрек, карчай-балкар һ.б. халыклар тәшкил итә. Бүгенге сөйләм телебез, әдәби телебез мөстәкыйль булса да, кардәш телләр арасында аермалар шактый.

Төрки халыклар бер-берсеннән сөйләм теле, аерым гореф-гадәтләре, мәдәни һәм сәяси дөньялары белән аерылып торсалар да, барлык төркиләрнең теле, мәдәнияте бик борынгы дәверләрдән үк формалашкан уртак катламнан үсеп чыккан. Бердәмлекнең нигезен төрки тел,

гомумтөрки матди һәм рухи мәдәният, этнография, йола-гадәтләр, фольклор, әдәбият һәм уртак тарихи үткәнебез тәшкил итәләр [12].

Бүгенге глобальләшү шартларында телләрне саклау һәм үстерү мәсьәләсе төрки телләрдә дә гаять актуаль. Билгеле ки, Россиядә генә түгел, башка чит төбәкләрдәге төрки халыклар да бүгенге көндә физик һәм тел ягыннан ассимиляция процессы кичерә**.** Галимнәр бигрәк тә Алтайда яшәүче кумандин, телеут, челкан, шорларның халык саны бик азаю сәбәпле, телләре югалып бара дип аңлаталар. Башкорт, үзбәк кебек күп санлы төрки халыкларда да туган тел мәсьәләсе кискен тора. Казах галимнәре дә туган телнең киләчәге өчен борчылалар. Белгечләр фикеренчә, киләчәктә төрки телләрнең сакланып калуы өчен, үзара якынаерга һәм төрки телле халыкларга, һичшиксез, берләшергә кирәк. Төрки дөньяны берләштерә торган мотивлар буларак түбәндәгеләр билгеләнә.

1. Графика мәсьәләсе. Бүгенге көндә төрки халыклар 3 төрле графика куллана: кириллица, латин, уйгыр язуы. Россия федерациясендә яшәүче төрки халыклар - кириллица, әзерҗайҗан, төрек, үзбәк, каракалпак һ.б. телләр - латин, кытайда яшәүче уйгырлар гарәп язуы кулланалар.

Билгеле булганча, 2017 нче елны Казахстан да латинга күчү канунын кабул итте. Бу җитди адым телне саклап калудан тыш, аны заманча мәгълүмат теленә дә әверелдерәчәк, дип ашана алар һәм 2025 нче елга кирилл хәрефләреннән латин графикасына күчеп бетәргә ниятлиләр.

Тарихка кз салсак, 90 нчы елларда алфавит системасында яңа реформалар белән башланып китә - төрки телләрнең латинга кайту мәсьәләсе көн кадагына килеп баса. Әзерҗайҗан, үзбәк, каракалпак кебек кайбер төрки халыклар 90 елларда латинка кайтсалар да, 70 ел эчендә дүртенче тапкыр алфавит алыштыру мәсьәләсе әлбәттә җиңел генә хәл ителә алмый. Татар телендә дә 80 еллар ахыры – 90 еллар башында күтәрелеш булып ала. Төрле фикерләр, тәкъдимнәр, каршылыклар була. Гамәлдәге кириллицага кабат өстәмә хәрефләр кертергә кирәк дигән мәсьәлә дә күтәрелә. Икенче юнәлештә баручылар Яңалифны кире кайтаруны яклап чыгалар. Ахыр чиктә РФдә бары тик кириллица гына гамәлдә булырга тиеш дип хәл ителә. Шул рәвешле алфавитка күчү мәсьәләсе хәл ителми кала.

Галимнәр төрки телләрнең латин графикасына күчүе бүгеге көндә төрки халыкларны берләштерүче көч булып торуын ассызыклыйлар. Татарларга да акрынлап латин графикасына күчә башларга кирәк дип саныйлар [2]. Моның төп сәбәбе алфавитта һәм орфографиядә техник

җитешсезлекләр белән генә билгеләнми әлбәттә. Тарихчы галимнәр искәртүенчә, “латин графикасы – татар сөйләменең үзенчәлекләрен генә чагылдырып калмыйча, мәгълүмат системаларында үз урыныбызны табарга мөмкинлек бирәчәк”[15].

2. Икенче мәсьәлә - төрки терминология мәсьәләсе. Тарихтан мәгълүм булганча, XX гасыр башыннан 1917 нче елгы революциягә кадәр дәвам иткән әлеге чорда терминнар буларак, төки телләргә күбрәк гарәп-фарсы алынмалары үтеп кергән. Октябрь инкыйлабыннан башлап 1980 нче еллар азагына хәтле сузылган икенче этапта исә аларны рус сүзләре һәм рус теле аша кергән интернационализмнар кысрыклап чыгарган. Бу, беренче чиратта, совет чоры идеологиясе белән бәйле. Шуңа терминнар ясауда рус теленә таяну, барлык телләр өчен универсаль терминнар эшләргә омтылыш өстенлек итте. XX гасыр азагында башланган һәм хәзер дә дәвам итә торган өченче этапта терминологияне кабат карау, яңарту эше алып барыла. 80 нче еллар азагында - 90 нчы еллар башында илдә җәелгән демократия терминологияне яңабаштан карау мөмкинлеген тудырды [3].

Советлар союзы чорында Милли республикаларда да төрки терминологик система рус теле йогынтысында формалаша. Гомумән, телнең лексик составына рус теленең тәэсире аеруча көчле була. Элекке СССР яшәүче халыкларның телләрендә барлык иҗтимагый-сәяси, фәнни терминология рус теленнән алынган яисә рус теле тәэсирендә формалашкан.

Терминологияне унификацияләү фән үсешен чагылдырган фәнни төшенчәләрнең, атамаларның булуына бәйле. Казах телендә дә, татар, башкорт, төрек, әзербайҗан телендә һ.б. телләрдә дә терминология системасы көн кадагында тора. Әйтик, төрекләр терминнар мәсьәләсен төрек теле җирелегендә ясалган яңа сүзләр исәбенә хәл итәргә тырышалар. Бүгенге көндә терминология өлкәсендә зур эш алып бару сорала. Белгечләр шуны күрсәтә, төрки халыкарның галимнәре берләшеп бердәм электрон терминологик базасын һәм төрки телләрнең милли корпусын булдыру куелган максатларга ирешүгә ярдәм итәр иде. Бәлки, бөтен тюркологларның, лингвистларның, әдәбиятчыларның, тарихчыларның бергә берләшеп, гомуми уртак фәнни терминологиясен булдыру кирәктер дигән тәкъдимнәр дә еш яңгырый.

3. Төрки телләрне компьютер системаларында, Интернетта яшәтү, челтәрдә мәгълүмат туп-лау, саклау, алмашу, тапшыру чарасы итү – шулай ук көн кадагындагы мәсьәлә.

Интернет - зур мөмкинлекләр бирүче, кешеләрнең яшәү рәвешен үзгәрткән иң көчле заманча корал. Төрки телләр, шул исәптән татар теле мәгълүмат системаларында үзенең лаеклы урынын табарга тиеш. Шунысы куанычлы, соңгы еллардагы хәлләрне күзәтсәк, татар теленең

интернетта кулланылышы арта. Төрле социаль челтәрләр, аралашу чараларын татарчалаштыру яшьләрдә телгә кызыксыну һәм ихтирам арттыра.

Академик галим Ж.Сөләйманов фикеренчә, инглиз, урыс телләреннән һич тә калышмыйча, хәзерге глобальләштерү заманында телебезне компьютер теле итү зарур. “Моны Төркия, Казахстан, Татарстанда, башка төрки республикаларда да бик яхшы аңлыйлар һәм узган гасырның туксанынчы елларыннан башлап әлеге юнәлештә эшләр алып барыла. Әйтик, казахлар компьютер термин-төшенчәләре иҗат итеп китаплар, сүзлекләр чыгара. Төркиядә дә тик ятмыйлар. Якут, алтай, гагауз, чуаш, бурят, башкортлар үз телләрен компьютерга кертергә тырышып, үзенчә программалар төзеп, әлегә кадәр бик актив эшләп килә. [4]. Татар теле дә бу эштә читтә калмый. Бүгенге көндә Гамәли семиотика галимнәре тарафыннан татар телен интернетка кулланышка кертүдә зур эш алып барыла. Татар сөйләм телен текстка әйләндерү программасы һәм язма текстны "сөйләштерү" программасы эшләнгән. Бүгенге көндә алар татарча мобиль кушымталар булдыру, татарча-русча, русча-татарча сүзлекләр төзү белән шөгыльләнәләр. Бүгенге көндә Гамәли семиотика институтының Яндекс ширкәте белән берлектә эшләнеп килгән русчадан-татарчага онлайн тәрҗемәчесистемасы инде киң кулланышта [8].

Татарча язма корпус турында да әйтеп узарга кирәк. Татар теленең системасы, хәле, алдагы көне белән кызыксынучы шәхесләрне күздә тотып төзелгән әлеге язма корпус татарча дөрес язу, сөйләү, текстны тану, татарча тел берәмлекләрен эзләү кебек эшләр башкара. Дөрестән дә, бу корпус татар телен корпуслы лингвистика кысаларында өйрәнүче белгечләр өчен зарури чыганак [9].

Бүгенге көндә программалаштырылган дөрес итеп тәрҗемә итәргә өйрәтә торган модельләр, калыплар төзү әһәмиятле. Казахлар – үз телләренең, төрекләр – үз телләренең, татарлар - татар теленең электрон база-нигезен булдыру ниятеннән, электрон кулланышта булган бөтен сүзне шунда кертергә тырышалар. Аңлашыла ки, телләр өчен тәрҗемә программалары тө-зергә, туган телдә эш кәгазьләре, китаплар чыгарырга кирәк [4].

Телне мәгълүмат-коммуникация технологияләре ярдәмендә популярлаштыруда интернетның роле бәхәссез. Билгеле булганча, 2018 нче елны Истанбулда төрки дөньяның үз социаль челтәре – “Төрки туй” коммуникация платформасы эшли башлады. (җитәкчесе Фуркан Мажит). “TÜRKTOYU” бер тамырдан килүче, төрки телләрдә сөйләшүче халыкларның бер-берләре белән уңайлырак аралашулары өчен булдырылган. Төрки халыклар һәм аларга тугандаш милләтләр бу платформа ярдәмендә үз социаль челтәрләрен куллана алачаклар. “TÜRKTOYU”

челтәре “Төрки дөньяны таны!” шигаре белән эшли. Анда төрки дөнья белән бәйле хәбәрләр, мәгълүматлар урын алачак дип күзаллана. Челтәр азәрбайҗан, казак, кыргыз, төрек, төрекмән, үзбәк телләрендә эшләячәк икән. Россия Федерациясендәге төрки халыклар да исәпкә алынган, шунлыктан рус теле дә, шулай ук халыкара тел буларак инглизчә дә кулланылачак. Санап кителгән телләр арасыннан кем кайсысын кулланырга теләсә, шул телдә аралаша, языша һәм укый алачак. Оештыручылар белдерүенчә, алга таба, бәлки, челтәр татар, башкорт, чуваш, алтай һәм Россиядәге башка төрки халыкларның телләрендә дә хезмәт күрсәтер [5].

4. Төрки дөньяның бай тарихы бар. Бүгенге көндә тагын бер мөһим мәсьәлә - төрки дөнья өчен уртак булган гомуми тамырларны табу. Бу тамырлар төрки халыкның тарихи лексик катламында, халык авыз иҗатында, эпик әсәрләрендә, гореф-гадәтләрендә, сәнгатендә саклана. Билгеле булганча, язма әдәбиятның тарихы гомумтөрки язма истәлекләргә барып тоташа. Бу V-VI гасырларга караган рун графикасында язылган Орхон-Енисей язмаларында, X-XI гасырларга караган Мәхмүт Кашгарый, Йосыф Баласагунлы, Әхмәт Йүгнәки тарафыннан язылган фәнни хезмәтләрдә, этик-дидактик поэмаларда чагыла. Күп кенә төрки халыкларда тарихи язма истәлекләрне тикшерү, фәнни яктан өйрәнүдә җитди эш алып барыла. Мәсәлән, төрек галимнәре, моның әһәмиятен аңлаган хәлдә, борынгы кулъязма истәлекләрнең лексик үзенчәлекләрен өйрәнүгә аеруча зур игътибар бирәләр. Бу тикшеренү нәтиҗәләрнен бастыру, гамәли кулланылышка кертү төрки халыкларны, телләрне ныгытуда һәм саклауда нәтиҗәле чара булыр иде [12].

5. Телләрнең ассимиляцияләшүен булдырмау максатында төрки телләрнең әһәмиятен арттыру кирәк. Галимнәр фикеренчә, моның өчен төрки халыкларга берләшеп, гомум төрки тел булдыру зарур. Гомумтөрки тел барлык төрки халыклар өчен якын булган тел һәм мәдәният өлкәләрендә үзара хезмәттәшлеген ныгытуга һәм халыкларны үзара якынайтуга ярдәм итәр иде дип аңлаталар алар. Гомумтөрки әдәби тел булдыруның уңай яклары итеп түбәндәгеләр күрсәтелә: 1) төрки халыкларың үзара аралашу мөмкинлеге киңәя; 2) аерым төрки телләрнең әһәмияте артачак; 3) төрки халыклар өчен уртак туган тел була; 4) бу телне өйрәнү башка чит телне өйрәнүгә караганда җиңелрәк; 5) бу тел фән, техника һәм дәүләт теле була алыр иде.

Гомумтөрки тел булдыру турында хәзерге тюркологиядә сөйләшүләр бара, күп төрле фикерләр яңгырый, концепцияләре тәкъдим ителә, методикалар эшләнә. Гомумтөрки тел буларак кайсыдыр бер төрки тел түгел, ә барлык төрки телләр өчен урталыкта торган “урта төрки тел” булдыру күздә тотыла. “Анатөрки тел”, “Төрки”, “Урта төрки тел”, “Төрки эсперанто” дигән

терминнар да тәкъдим ителәә. Мәсәлән, үзбәк галиме Б. Кәримов фикеренчә, урта төрки тел күпчелек төрки халыкларда кулланылган сүзләр, кагыйдәләр нигезендә төзелергә тиеш. Әйтик, күпчелек төрки халыклар китапны китап дип атый икән, телгә шушы сүз кертелә. Галимнәр фикеренчә, бу тел милләтара аралашу, мәгълүмат туплау теле була алыр иде, тел ягыннан да элемтәләр тәэмин ителер иде. Тарихтан мәгълүм булганча, XVII-XVIII йөзләрдә бөтен төрки халыклар үзера татар телендә аралашкан, язма тел дә аралашу теле дә шул телгә нигезләнгән. Россиянең көнчыгыш илләре белән аралашуда да татар теле төп рольне үтәгән. Төрле көнчыгыш илләре, Урта Азия белән дипломатик мөнәсәбәтләр татар теленә алып барылган. Татар галимнәре, тарихчылары фикеренчә, ниндидер ясалма тел уйлап табарга кирәкми, структурасы, системасы камил, төзек булган татар еле бу функцияне үти алыр иде [15].

Төркиянең Кыркларэли университеты Бүгенге чор төрки телләр һәм әдәбиятлары бүлеге галиме, доцент филология фәннәре докторы Бүләнт Бәйрәм татар телен бүгенге көндә төрки телләр арасында иң камил язу телләренең берсе дип саный. Аның фикеренчә, “Татар телен борынгы төрки язу теленең традицияләрен дәвам итүче тел, дип бәяләргә мөмкин. Төрки халыкларда татар теле белән эшләнгән гаҗәеп бай мәдәни байлык җыелмасы бар. Бигрәк тә XIX гасырдан алып, бүгенге көнгә чаклы татар телендә иҗат ителгән әдәби әсәрләр бөтен төрки халыкларга йогынты ясавы ягыннан әйтеп бетергесез зур әһәмияткә ия. Моннан чыгып мин, татар телен мәдәни бер халыкның ана теле итеп күрәм. Аның бар булуын, кулланылуын, укытылуын, башка милләтләргә дә өйрәтелүен хуплап, татар теле киләчәк гасырларда да әһәмиятле миссиясен җиткерүен дәвам итәр, дип ышанам”[11].

Соңгы 20 ел эчендә Төркия һәм Азәрбайҗанда күп кенә төрки дәүләтләр һәм халыклар дуслыгы корылтайлары үткәрелеп килә. Төрки халыкларның мәдәниятен үстерүче ТЮРКСОЙ дәүләтара оешмасы да гаять актив эшли. Төрки дәүләтләрнең парламентара ассамблеясы даими рәвештә Бакуда җыелып тора. 1991 елдан халыкара иҗтимагый оешма – Бөтендөнья төрки халыклар ассамблеясы (БТХА) эшли. Төрки дөньяда күптән инде «Евровидение» рәвешендәге «Тюрковизйон» дигән җыр бәйгесе үткәрелә. Төрки яшьләр фестивале узуын да, еш кына төрки-мөселман театрлары фестивале үткәрелүен дә онытмыйк.

Эчке икътисади-мәдәни багланышлар төрки дөньяны даими ныгытып һәм бәйләп тора. Төрки дөньяны берләштерә торган әлеге мәдәни багланышлар нигезендә киләчәктә идеология дә барлыкка килергә мөмкин. Аның тууы өчен төркиләрдә тагын да киңрәк һәм тирәнрәк нигез – «дөньяга уртак караш» булырга тиеш.

Югарыда әйтелгәннәрне күздә тотсак, бүгенге көндә төрки телләрне саклау мәсьәләсе генә түгел, аларны үстерү дә мөһим. Гомумтарихи үткәненә таянып, заманча технологияләргә нигезләнеп, төрки телләрнең киләчәге якты булыр дип ышанасы килә.

**Әдәбият**


1. Баско Н.В. Развитие русского языка в условиях глобализации // Языковая политика и языковые конфликты в современном мире. - М., 2014. - С. 252-256
2. Безгә акрынлап латинга күчә башларга кирәк. Режим доступа: http://atnya-rt.ru/news/%D2%97%D3%99mgyiyat/bezg-akryinlap-latinga-kch-bashlarga-kirk-galim-fa https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]
3. Гарифуллин В.З. Татарча терминнар үсешендә журналистиканың роле// Режим доступа: http://docs.exdat.com/docs/index-364153.html) https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]
4. Татар теле һәм цифрлы технологияләр: әзер программалар бар, куәтле серверлар юк. Режим доступа: https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]
5. Истанбулда төрки дөньяның социаль челтәре – “Төркитуй” эшли башлады... Режим доступа: tatar-inform.tatar›news/2018/09/23/172073/ https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]
6. Латин графикасы казахка кирәк, ә татарга? Режим доступа: https://beznen.ru/basma/2016-17/latin-grafikasi-kazahka-kirek-e-tatarga. https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]
7. Питер Л. Бергер. Культурная динамика глобализации // Многоликая глобализация / Под ред. П.Бергера и С.Хантингтона; Пер. с анг. В.В. Сапова под ред. М.М. Лебедевой. – М.: Аспект Пресс, 2004. – С. 10.
8. Татар теле һәм цифрлы технологияләр: әзер программалар бар, куәтле серверлар юк . Режим доступа: https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-

programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/ https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]

9. Татар теленң язма корпусы. Режим доступа: http://www.corpus.tatar/tt https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]

10. Телебез үлмәсен дисәк… Режим доступа: http://maydan.tatar/telebez-ulmesen-disek/ https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]

11. Төрек галиме татар телен төрки телләр арасында иң камил язу телләренең берсе дип саный. - Шәһри Казан 2017, 5 ноябрь Режим доступа: https://tatar-inform.tatar/news/2017/11/04/151680/ https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]

12. Төрки әдәби дөньяны берләштерүче мотивлар // dumrt.ru https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]

13. Тюркские языки в условиях глобализации (этносоциологический анализ татарского языка). Коллективная монография / Сост.: Габдрахманова Г.Ф., Исхакова З.А., Мусина Р.Н. – Астана: Кантана-пресс, 2011. – 396 с.

14. Урта төрки тел кирәкме?/ Режим доступа: http://muslumirc.ru/news/stati/urta-trki-tel-kirkme https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]

15. Хәким Р. Кем син татар Режим доступа: http://miraska.narod.ru/tatars/hakim2.htm https://intertat.tatar/society/tatar-tele-m-tsifrly-tekhnologiyal-r-zer-programmalar-bar-ku-tle-serverlar-yuk/[Дата обращения: 16.01.2019]